# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Дәүләткә карамаган пенсия фондлары турында

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Әлеге Закон белән җайга салынучы мөнәсәбәтләр

Әлеге Закон дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты өлкәсендә икътисадый һәм социаль мөнәсәбәтләрне, дәүләткә карамаган пенсия фондларының эшчәнлеген җайга сала, шулай ук аларның эшчәнлекләрен дәүләт тарафыннан тикшереп торуның төп принципларын урнаштыра.

Дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты өлкәсендә мөнәсәбәтләр Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актлары белән дә җайга салына.

Әлеге Законның гамәлдә булуы дәүләт пенсия тәэминатына кагылмый.

2 статья. Дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты

Дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты - пенсия кертемнәрен максатчыл җыюны һәм аларны исәпкә алуны, активларны барлыкка китерүне, аларны инвестицияләүне, физик затларга (фондта катнашучыларга) пенсияләр түләүне, шулай ук дәүләткә карамаган пенсия фондының фондка акча кертүчеләр һәм фондта катнашучылар алдындагы йөкләмәләрен үтәүгә юнәлдерелгән башка вазыйфаларны үз эченә алучы эшчәнлекнең аерым төре ул.

3 статья. Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр

Дәүләткә карамаган пенсия фонды (алга таба - фонд) - әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә лицензия алган һәм эшчәнлеге-

нең төп төре дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты булган коммерциягә карамаган махсуслаштырылган социаль тәэминат оешмасы ул.

Фондка акча кертүче (алга таба - акча кертүче) - дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турындагы шартнамә буенча пенсия кертемнәрен кертүче юридик яисә физик зат ул.

Фондта катнашучы (алга таба - катнашучы) - дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турындагы шартнамә нигезендә үз файдасына пенсия кертемнәре һәм пенсия түләүләре алучы физик зат ул.

Фондта катнашучы үз файдасына акча кертүче сыйфатында да булырга мөмкин.

Пенсия кертемнәре - катнашучылар файдасына акча кертүче тарафыннан кертелүче акчалар ул.

Пенсия счеты - пенсия кертемнәренең килерен, инвестиция керемен исәпләүне, пенсия түләүләрен һәм башка түләүләрне чагылдыручы аналитик исәпкә алу рәвеше ул.

Пенсия җыелмалары - пенсия счетында чагылдырылган һәм фондның катнашучыларга пенсия түләүләре буенча йөкләмәләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән акча ул.

Пенсия схемалары - пенсия җыелмаларын һәм түләүләрен барлыкка китерү шартларының һәм тәртибенең бергәлеге ул.

Пенсия түләүләре - дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турындагы шартнамә шартлары нигезендә катнашучыга түләнә торган акчалар ул.

Исәпләрне өзү суммасы - дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турында шартнамәне өзгәндә акча кертүчегә яисә катнашучыга фонд кагыйдәләре нигезендә түләнүче йә башка фондка күчерелүче акчалар ул.

Пенсия резервлары - пенсия түләүләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән акчалар тупланмасы ул.

Пенсия активлары - пенсия җыелмаларын һәм дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турындагы шартнамәләр буенча фонд кабул итеп алган йөкләмәләрне тәэмин итү резервларын барлыкка китерү өчен билгеләнгән акчалар ул.

Инвестиция кереме - пенсия активларын һәм фондның үз акчаларын инвестицияләү нәтиҗәсендә фонд тарафыннан алынган акчалар ул.

Татарстан Республикасының вәкаләтле дәүләт органы (алга таба – вәкаләтле дәүләт органы) – дәүләткә карамаган пенсия фондларының эшчәнлегенә рөхсәт бирү һәм аны тикшереп тору, фондларга лицензияләр бирү һәм кире алу вазыйфаларын үтәүче Татарстан Республикасы дәүләт органы ул.

## II бүлек. Фондларны төзү, теркәү һәм эшчәнлекләрен лицензияләү

### 4 статья. Фондларны төзү

Фондларны гамәлгә куючылар юридик һәм физик затлар булырга мөмкин.

Фонд үз йөкләмәләре өчен үз карамагындагы барлык мөлкәте белән законнар нигезендә җавап тота.

Фондның гамәлгә куючылары, акча кертүчеләре һәм катнашучылары, шулай ук дәүләт фонд йөкләмәләре буенча җавап тотмый, фонд та үзенең гамәлгә куючылары, акча кертүчеләре, катнашучылары һәм дәүләт йөкләмәләре буенча җавап бирми.

### 5 статья. Фонд идарәсе һәм аның эшчәнлеген тикшереп тору органнары

Фонд идарәсе органнарының төзелеше һәм аларның вәкаләтләре фондның гамәлгә кую документларында законнар нигезендә билгеләнә.

Фонд идарәсенең органнары фонд советы һәм башкарма дирекция була.

Фонд эшчәнлеген тикшереп торуны гамәлгә ашыручы органнар попечительләр советыннан һәм ревизия комиссиясеннән гыйбарәт.

Фонд идарәсенең иң югары органы фонд советы була. Фонд советы фондны гамәлгә куючылар тарафыннан сайлана. Фонд советының төзелеше һәм тәртибе фонд уставы белән законнар нигезендә билгеләнә.

Башкарма дирекция законнар, фонд уставы һәм башкарма дирекция турында фонд советы раслаучы нигезләмә нигезендә фонд эшчәнлегенә идарә итә.

Попечительләр советы фонд эшчәнлеген тикшереп тора һәм

фондка акча кертүчеләрнең һәм фондта катнашучыларның мәнфәгатьләрен яклауны гамәлгә ашыра. Попечительләр советының барлыкка килү һәм эшләү тәртибе, шартлары фонд уставы һәм попечительләр советы турындагы нигезләмә белән билгеләнә. Фондның попечительләр советына акча кертүчеләрнең һәм катнашучыларның вәкаләтле вәкилләре керә, карар кабул иткәндә тавышларның кимендә яртысы аларныкы була.

6 статья. Фондны дәүләт тарафыннан теркәү һәм фондның гамәлгә кую документлары

Фондны дәүләт тарафыннан теркәү законнар нигезендә башкарыла.

Вәкаләтле дәүләт органы бирә торган лицензияне алган көннән фонд әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән эшчәнлеген башкару хокукына ирешә.

Фондның гамәлгә кую документлары уставтан һәм гамәлгә кую шартнамәсеннән гыйбарәт була. Фондның уставы аны гамәлгә куючылар (гамәлгә куючы) тарафыннан раслана. Фондны төзү тәртибе аны гамәлгә куючылар төзегән гамәлгә кую шартнамәсе белән билгеләнә.

Фонд уставында түбәндәгеләр булырга тиеш:

фондның тулы һәм кыскартылган исеме, бу чакта аның исемендә "дәүләткә карамаган пенсия фонды" сүзләре, аның кайда урнашуы турындагы белешмәләр булырга тиеш;

фонд эшчәнлегенең предметы һәм максатлары турындагы нигезләмәләр;

фонд идарәсе органнарының төзелеше һәм вәкаләтләре турында, идарә органнарындагы вәкиллек нормалары турында белешмәләр;

урындагы затларны урыннарына билгеләп кую һәм урыннарыннан азат итү, карарлар кабул итү, хисаплар бастырып чыгару, фонд эшчәнлеген тикшереп тору, фондны үзгәртеп кору һәм ябу, пенсия резервларын урнаштырудан килгән керемнәрне бүлү тәртибе турында, шулай ук фондны япканда мөлкәтне бүлү тәртибе турында нигезләмәләр.

Гамәлгә кую шартнамәсендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

фондның тулы һәм кыскартылган исеме, кайда урнашуы турында белешмәләр;

269



фонд эшчәнлеге предметы һәм максатлары турында нигезләмәләр;

гамәлгә куючылар составы турындагы белешмәләр;

фонд тәзегәндә гамәлгә куючылар керткән акчаларның гомуми күләме турында белешмәләр;

фонд идарәсе органнары турында һәм фонд эчшәнлегенә идарә итү тәртибе турында белешмәләр;

фонд төзү һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү буенча фондны гамәлгә куючыларның йөкләмәләре исемлеге, гамәлгә куючыларның мөлкәтне фондка тапшыру шартлары һәм гамәлгә куючыларның гомуми кертемне барлыкка китерүдә катнашулары турында белешмәләр;

фондны гамәлгә куючылар составына өстәмә кабул итү һәм фондны гамәлгә куючылар составыннан чыгу тәртибе турында нигезләмәләр.

<u>7 статья.</u> Фондның эшчәнлеген лицензияләү

Фонд эшчәнлеге һичшиксез лицензияләнергә тиеш. Фондның эшчәнлеген лицензияләү законнарда билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан башкарыла.

<u>8 статья.</u> Фондларның берләшмәләре

Фондлар үз эшчәнлекләрен җайга салу өчен, уртак проектларын, программаларын гамәлгә ашыру өчен һәм фонд катнашучыларының һәм акча кертүчеләренең мәнфәгатьләрен яклау өчен үз ихтыярлары белән берлекләргә, ассоциацияләргә берләшергә мөмкин.

Фондларның берлекләре, ассоциацияләре дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты белән шөгыльләнергә хокуклы түгел.

Ш бүлек. Фонд эшчәнлеге

<u>9 статья.</u> Фондның төп максаты

Фонд үзенең устав эшчәнлеген әлеге Закон, башка норматив-хокукый актлар, шулай ук фонд уставы һәм кагыйдәләре нигезендә башкара.

Фонд эшчәнлегенең төп максаты гражданнарны - фондта кат-

нашучыларны пенсияләр түләү һәм социаль тәэминатның, хезмәт күрсәтүләрнең юлдаш төрләрен башкару рәвешендә социаль яктан тәэмин итүдән гыйбарәт.

10 статья. Фондның төп вазыйфалары

Фонд түбәндәге төп вазыйфаларны башкара:

- законнарны исәпкә алып, фонд тарафыннан дәүләткә карамаган пенсия тәэминатын һәм социаль тәэминатның, хезмәт күрсәтүләрнең юлдаш төрләрен тормышка ашыру шартларын әзерли;
- дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турында акча кертүчеләр белән шартнамәләр төзи;
- пенсия кертемнәрен җыя һәм туплый;
- акча кертүчеләрнең һәм катнашучыларның пенсия счетларын алып бара, кагыйдәләрдә яисә пенсия шартнамәсендә каралган вакытларда елга кимендә бер мәртәбә фонд акча кертүчеләргә һәм катнашучыларга пенсия счетларының торышы турында мәгълүмат бирә;
- пенсия активларын һәм үз акчаларын инвестицияли;
- инвестиция керемен бүлә;
- актуар исәп-хисаплар уздыра;
- фондка акчаларның вакытында һәм тулысынча керүен тикшереп тора;
- пенсия түләүләрен һәм социаль тәэминатның, хезмәт күрсәтүләрнең шартнамәдә билгеләнгән башка төрләрен башкара;
- билгеләнгән рәвешләрдә һәм билгеләнгән вакытларда үз эшчәнлеге турында дәүләт органнарына хисап бирә;
- әлеге Законга һәм фондның устав максатларына каршы килми торган башка вазыйфалар башкара.

Фонд, нинди максатларда төзелгән булса, шул максатларга ирешү өчен кирәкле һәм шул максатларга туры килерлек эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләре белән законнар нигезендә шөгыльләнергә хокуклы. Бу эшчәнлек төрләренең исемлеге вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан раслана. Эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен фонд хуҗалык җәмгыятьләре төзергә яисә аларда катнашырга хокуклы.

11 статья. Фонд кагыйдәләре

Фонд кагыйдәләре - әлеге Закон нигезендә фонд тарафыннан әзерләнүче һәм фонд идарәсенең иң югары органы тарафыннан раслanучы дәүләткә карамаган пенсия тәэминатының рәвешләрен, тәртибен һәм шартларын законнар нигезендә билгеләүче документ ул.

Фонд кагыйдәләрендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турындагы шартнамәне төзү тәртибе;
- фонд тарафыннан кулланылучы пенсия схемаларының тасвирламасы;
- пенсия кертемнәрен кертү тәртибе һәм шартлары;
- катнашучының пенсия түләүләрен алу хокукы барлыкка килү очраклары;
- катнашучының пенсия җыелмаларына хокукы барлыкка килү фактын раслаучы пенсия таныклыгының (пенсия полисының, сертификатының) рәвеше;
- пенсия түләүләренең тәртибе һәм шартлары;
- фондның, акча кертүчеләрнең, катнашучыларның хокуклары һәм вазыйфалары;
- фондның акча кертүчеләр һәм катнашучылар адында җаваплылыгы;
- пенсия шартнамәсен үзгәртү яисә өзү тәртибе.

Фонд кагыйдәләрендә законнарга каршы килмәүче бүтән нигезләмәләр дә булырга мөмкин.

Фонд кагыйдәләренә акча кертүчеләр һәм (яисә) катнашучылар хокукларына һәм вазыйфаларына кагылучы үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү күрсәтелгән затлар ризалыгы булганда гына йә, акча кертүчеләр һәм катнашучылар фонд кагыйдәләренә кертелүче үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән килешмәгән очракта, акча кертүчеләргә һәм (яисә) катнашучыларга исәпләрне өзү суммасын биреп яисә аны башка фондка күчереп фондтан чыгу хокукын биргән килеш, аларга алдан хәбәр итү шартларында гына мөмкин була.

12 статья. Дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турында шартнамә

Дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турындагы шартнамә (алга таба - пенсия шартнамәсе) катнашучы файдасына фонд белән акча кертүче арасында төзелүче килешү ул, шуның нәтиҗәсендә акча кертүче пенсия кертемнәрен билгеләнгән чорларда һәм билгеләнгән күләмнәрдә кертергә йөкләмә ала, ә фонд исә пенсия шартнамәсендә билгеләнгән очраклар барлыкка килгәндә һәм сайлап алынган пенсия схемасы һәм фонд кагыйдәләре нигезендә катнашучыга пенсия түләүләрен бирергә йөкләмә ала.

Пенсия шартнамәсендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- якларның исемнәре;
- шартнамәнең предметы;
- якларның хокуклары һәм вазыйфалары;
- пенсия кертемнәрен тапшыру тәртибе һәм шартлары;
- пенсия түләүләрен алу тәртибе һәм шартлары;
- катнашучы пенсия түләүләрен алырга хокуклы булырлык хәлләр;
- пенсия схемасы төре;
- үз йөкләмәләрен үтәмәгән өчен якларның җаваплылыгы;
- шартнамәнең гамәлдә булу һәм өзелү чоры;
- шартнамәне үзгәртү, өзү тәртибе һәм шартлары;
- бәхәсләрне җайга салу тәртибе;
- якларның реквизитлары.

Пенсия шартнамәсендә якларның үзара килешүе буенча билгеләнгән башка шартлар да күрсәтелергә мөмкин һәм пенсия шартнамәсе алыш-бирешләр чынлыгының граждан законнарында каралган гомуми шартларына туры килергә тиеш.

Дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турында фонд тарафыннан төзелүче шартнамәләр фонд кагыйдәләренә каршы килмәскә тиеш.

13 статья. Пенсия схемалары

Пенсия тәэминатының төп схемалары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- кертемнәрнең билгеләнгән күләмнәре күрсәтелгән схема -

катнашучыга бирелүче пенсия түләүләрен барлыкка китерү тәртибе ул, бу вакытта дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турындагы шартнамәнең шартлары белән акча кертүченең пенсия кертемнәрен кертү күләмнәре һәм тәртибе, фондның инвестиция керемен исәпләү күләмнәре һәм тәртибе билгеләнә. Пенсия түләүләренең күләмнәре фонд кагыйдәләре һәм дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турындагы шартнамә шартлары нигезендә пенсия счетында барлыкка килгән җыелмалар күләменә бәйле була;

- түләүләрнең билгеләнгән күләмнәре күрсәтелгән схема - катнашучы өчен пенсия түләүләрен барлыкка китерү тәртибе ул, бу вакытта пенсия түләүләренең күләме һәм аны бирү тәртибе дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турындагы шартнамәнең төзелгән мизгелендәге шартлары белән билгеләнә.

Фондлар пенсия тәэминатының катнаш схемаларын әзерли һәм куллана алалар.

<u>14 статья.</u> Пенсия счетлары

Фонд пенсия счетларын фондта катнашучылар алдындагы йөкләмәләре үтәлеп беткәнче алып барырга тиеш.

Пенсия счетлары акча кертүченең шәхси пенсия счетлары һәм катнашучының исемле пенсия счетлары рәвешендә булырга мөмкин.

Шәхси пенсия счетында күрсәтелгән акчалар белән - акча кертүче, ә исемле пенсия счетындагы акчалар белән катнашучы эш итәргә хокуклы.

Катнашучыларның исемле пенсия счетындагы акчаларын мирас итеп калдыру тәртибе һәм акча кертүчеләрнең исемле пенсия счетларын, хокукларын күчерү тәртибе законнар белән җайга салына.

<u>15 статья.</u> Фонд акчалары

Фонд акчалары пенсияләр активыннан һәм фондның үз акчаларыннан тора.

Пенсия активлары акчалата (шул исәптән чит ил валютасы белән), кыйммәтле кәгазьләр, күчемле һәм күчемсез мөлкәт белән бирелергә мөмкин, һәм ул түбәндәгеләр исәбеннән барлыкка килә:

- пенсия кертемнәре;

- пенсия җыелмаларын һәм резервларын төзү өчен билгеләнгән инвестиция кеременең өлеше;
- башка законлы кертемнәр.

Фондның үз акчалары түбәндәгеләр исәбеннән барлыкка килә:
- гамәлгә куючыларның устав фондына кертемнәре;
- инвестиция кеременең устав эшчәнлеген үтәү фонды чыгымнарын каплау өчен тотылучы өлеше;
- башка законлы кертемнәр.

Фондның үз средстволары акчалата (шул исәптән чит ил валютасы белән), кыйммәтле кәгазьләр, башка мөлкәт белән бирелергә мөмкин.

16 статья. Фондның пенсия активлары белән идарә итү

Фондлар пенсия активларын инвестицияләүне мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырырга һәм (яисә) пенсия активларын ышанычлы идарә шартнамәләре, йөкләмә шартнамәләре һәм башка шартнамәләр буенча законнар нигезендә юридик затларга - идарәчеләргә идарә итү өчен тапшырырга хокуклы.

Идарәчеләрнең (идарәченең) фонд (фондлар) активлары белән эш итүгә вәкаләтле дәүләт органының рөхсәте (лицензиясе) булырга тиеш.

Пенсия активларын инвестицияләү фондларының эшчәнлеге эшкуарлык эшчәнлегенә керми. Пенсия активларын инвестицияләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Фондның идарәчеләр белән үзара мөнәсәбәтләре әлеге Закон һәм фонд белән идарәче арасында төзелүче шартнамәләр нигезендә корыла. Идарәче фонд алдындагы йөкләмәләре буенча үзенең барлык мөлкәте белән җаваплы була.

Фондның төп эшчәнлеген планлаштыру һәм исәпкә алу эшчәнлекнең башка төрләрен планлаштырудан һәм исәпкә алудан аерым рәвештә гамәлгә ашырылырга тиеш.

17 статья. Инвестиция керемен бүлү

Инвестиция кереме фонд кагыйдәләрендә билгеләнә торган

тәртиптә фондның пенсия резервларын һәм үз резервларын төзүгә һәм фонд эшчәнлеген тәэмин итү буенча чыгымнарны каплауга җибәрелә.

Фонд эшчәнлеген тәэмин итүгә бүлеп бирелә торган инвестиция кеременең иң чик күләме әлеге Законны гамәлгә керткәннән соң фонд эшчәнлегенең беренче елында пенсия активларын инвестицияләүдән алынган керемнең 30 процентыннан һәм алга таба 20 процентыннан артмаска тиеш.

18 статья. Фонд вазыйфалары

Фонд түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:
- үз эшчәнлеген әлеге Закон нигезендә алып барырга;
- дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турындагы шартнамә шартларын үз вакытында үтәргә;
- пенсия счетларын алып бару юлы белән үз йөкләмәләренең шәхсиләштерелгән исәпкә алуын гамәлгә ашырырга;
- пенсия счетының торышы турында акча кертүчегә һәм катнашучыга хәбәр итәргә;
- акча кертүчеләрнең һәм фондта катнашучыларның хокукларын боза торган карарлар кабул итмәскә.

Фондның коммерция серен тәшкил итүче белешмәләрне өченче затларга бирергә хокукы юк, пенсия счетларының торышы һәм алар нигезендә бирелә торган пенсия түләүләре турындагы мәгълүмат коммерция серен тәшкил итә. Күрсәтелгән мәгълүмат өченче затларга законнарда билгеләнгән очракларда бары тик тикшерү, суд, салым органнары таләбе буенча гына бирелергә мөмкин.

Фондта катнашучылар һәм акча кертүчеләр алдында фондның йөкләмәләре йә дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турындагы шартнамәнең әлеге Законда билгеләнгән нигезләрдә гамәлдә булуы туктатылгач, йә фонд бетерелгән очракта катнашучылар белән акча кертүчеләр арасында исәп-хисаплар ясалгач кына туктатылырга мөмкин.

19 статья. Акча кертүчеләрнең һәм фондта катнашучыларның хокуклары һәм вазыйфалары

Акча кертүчеләрнең һәм фондта катнашучыларның хокуклары

һәм вазыйфалары әлеге Закон, башка закон актлары һәм хокукый-норматив актлар, фонд кагыйдәләре һәм пенсия шартнамәсе белән билгеләнә.

Акча кертүче түбәндәгеләргә хокуклы:

- законнар һәм дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты хакындагы шартнамә нигезендә дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турындагы шартнамәне әзәргә;

- фондтан законнар нигезендә үзенең шәхси пенсия счетының торышы турында мәгълүмат һәм башка мәгълүмат алырга;

- фонд уставы нигезендә фонд советы составына һәм фондның попечительләр советы составына керергә.

Акча кертүче дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турында төзелгән шартнамә шартларын үтәргә тиеш.

Катнашучы түбәндәгеләргә хокуклы:

- дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты турындагы шартнамә, әлеге Закон, фонд шартлары һәм кагыйдәләре нигезендә пенсия белән тәэмин ителергә;

- үз файдасына акча кертүче булып катнашырга;

- үзенең исемле пенсия счетының торышы турында фондтан мәгълүмат алырга.

Акча кертүчеләрнең һәм катнашучыларның әлеге Законда, башка закон актларында һәм норматив хокукый актларда, фонд кагыйдәләрендә һәм пенсия шартнамәсендә каралган бүтән хокуклары һәм вазыйфалары булырга мөмкин.

## IV бүлек. Исәпкә алу һәм хисап бирү

### 20 статья. Фондларда исәпкә алуны алып бару

Фондлар финанс-хуҗалык эшчәнлеген исәпкә алып баруны законнарда билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашыралар.

### 21 статья. Фондларның хисап бирүе

Фондлар законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм күләмнәрдә дәүләт, финанс һәм статистика хисабы бирәләр.

Фондның еллык финанс хисабы аудитор тарафыннан раслана. Аудитор тикшерүе нәтиҗәләре буенча төзелгән документ (акт)

фонд эшчәнлеге турында еллык хисапның аерылгысыз өлеше булып тора.

Фондның еллык финанс хисабы матбугатта басылып чыга.

## V бүлек. Фондны үзгәртеп кору һәм бетерү

<u>22 статья.</u> Фондны үзгәртеп кору

Фондны үзгәртеп кору, вәкаләтле дәүләт органы белән килештереп, пенсия шартнамәсе шартларын начарайтмаган килеш, фонд карарына таянып, законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Фондны үзгәртеп корганда аның хокукларын башкаларга күчерү законнар нигезендә башкарыла.

<u>23 статья.</u> Фондны бетерү

Фонд законнарда каралган тәртиптә бетерелергә мөмкин.

Фонд түбәндәге очракларда бетерелергә мөмкин:

- фондның мөлкәте үзенең максатларын гамәлгә ашыру өчен җитәрлек булмаса;
- фонд үз максатларына ирешә алмаса һәм фондның максатларын кирәгенчә үзгәртеп тә булмаса;
- фонд үз уставында каралган максатларыннан читкә тайпылса;
- законнарда каралган бүтән очракларда.

Фонд бетерелгәндә, эшләр белән идарә итү буенча барлык вәкаләтләр бетерү комиссиясенә күчә.

Бетерү комиссиясе составына вәкаләтле дәүләт органы вәкиле кертелә.

Фонд бетерелгәндә, аның мөлкәте акча кертүчеләр һәм фондта катнашучылар алдындагы йөкләмәләрне үтәгәннән соң законнарда каралган чиратлылык буенча барлык кредиторларның таләпләрен канәгатьләндерүгә җибәрелә, һәм ул гамәлгә куючыларның кеременә әверелдерелә алмый.

Фондның кредиторлар таләпләрен канәгатьләндергәннән соң калган мөлкәте фонд уставында күрсәтелгән максатларга юнәлдерелә.

Фонд бетерелү турында юридик затларның бердәм дәүләт ре-

естрына язма кертелгәннән соң - фондны бетерү тәмамланган дип, ә фондның гамәлдә булуы туктатылган дип санала.

## VI бүлек. Фондларның дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты буенча йөкләмәләрен үтәү гарантияләре

24 статья. Фондларның финанс тотрыклылыгын тәэмин итү шартлары

Дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия алу өчен вәкаләтле дәүләт органына фонд документлар биргән көнгә фондны гамәлгә куючыларның (гамәлгә куючының) катнашучыларның хокукларын яклауны тәэмин итү максатларында фондка акчалата кертелгән җыелма кертеме законнарда билгеләнгән күләмгә туры килергә тиеш.

Түләү сәләте һәм финанс тотрыклылыгы гарантияләрен тәэмин итү өчен фондлар дәүләтнең вәкаләтле органы тарафыннан расланган түбәндәге икътисадый нормативларны үтәргә тиешләр: пенсия активларын кертүнең ышанычлылык нормативын, фонд активларының һәм аның йөкләмәләренең тәңгәллеге нормативларын.

Фондның өченче затларның йөкләмәләрен үтәүне үз өстенә алырга, пенсия активларын һәм үз акчаларын залогка салырга, оештыру-хокукый рәвеше буенча гамәлгә куючыларның тулысынча мөлкәти җаваплылыгын күздә тотучы оешмаларда катнашырга, кыйммәтле кәгазьләр чыгарырга хокукы юк. Әлеге таләпләрне бозып эшләнгән алыш-биреш гамәлләре әһәмиятсез дип таныла.

25 статья. Фондның пенсия резервлары

Дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты буенча кабул ителгән йөкләмәләрне үтәү өчен фонд алынган пенсия кертемнәреннән һәм инвестиция кеременнән пенсия резервлары барлыкка китерә.

Пенсия резервларының структурасы фонд тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә. Пенсия резервлары фондның үз йөкләмәләрен үтәү өчен кирәкле күләмнәрдә барлыкка китерелә.

Пенсия резервларының норматив күләме Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Пенсия резервлары фондның, акча кертүчеләрнең, идарәченең

(идарәчеләрнең) бурычларын түләтү өчен алына алмый.

Фонд тарафыннан барлыкка китерелгән пенсия резервлары Татарстан Республикасының Республика бюджетына, җирле бюджетларга тартып алынмый.

<u>26 статья.</u> Иминләштерү резервын барлыкка китерү

Катнашучылар алдындагы йөкләмәләрне үтәүнең тотрыклылыгын тәэмин итү өчен фонд иминләштерү резервы барлыкка китерә.

Иминләштерү резервының норматив күләме һәм аны барлыкка китерү, аннан файдалану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Фондның иминләштерү резервы фондның, акча кертүчеләрнең, идарәченең (идарәчеләрнең) бурычларын түләтү өчен алына алмый.

Фондның иминләштерү резервы Татарстан Республикасының Республика бюджетына, җирле бюджетларга тартып алынмый һәм эшкуарлык эшчәнлеге өчен файдаланыла алмый.

<u>27 статья.</u> Мәҗбүри аудит

Дәүләткә карамаган пенсия фондлары ел саен финанс елы йомгаклары буенча үз исәбеннән бәйсез аудитор тикшерүе уздырырга тиеш.

Аудитор тикшерүе законнарда каралган тәртиптә бәйсез аудитор тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Пенсия активлары исәпкә алына торган аерымланган баланс буенча да, шулай ук дәүләткә карамаган фонд балансы буенча да исәпкә алу һәм хисап бирү документлары аудитор тикшерүе узарга тиеш.

<u>28 статья.</u> Берләштерелгән гарантияле фондлар һәм иминләштерү

Катнашучылар алдындагы йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү максатларында фондлар берләштерелгән гарантияле фондларны ихтыярый нигездә төзергә хокуклы.

Берләштерелгән гарантияле фондларны төзү принциплары һәм алар белән идарә итү тәртибе аларга керүче фондлар тарафыннан

законнар нигезендә билгеләнә.

Фондлар үзара иминләштерү җәмгыятьләрендә катнашырга, шулай ук фондларның катнашучылар алдындагы йөкләмәләрен үтәүнең өстәмә гарантияләрен тәэмин итүче иминләштерү шартнамәләре төзергә хокуклы.

Берләштерелгән гарантияле фондларның эшчәнлеген вәкаләтле дәүләт органы тикшереп тора.

## VП бүлек. Фондларның эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу

### 29 статья. Фондларның эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп тору

Фондларның эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп тору әлеге Закон таләпләрен үтәү, дәүләткә карамаган пенсия тәэминатын нәтиҗәле үстерү, акча кертүчеләрнең, катнашучыларның һәм дәүләтнең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатларында гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы территориясендә фондларның эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны вәкаләтле дәүләт органы гамәлгә ашыра.

Вәкаләтле дәүләт органының дәүләткә карамаган пенсия фондларына карата вазыйфалары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- фондларның эшчәнлеген лицензияләүдән;
- фондларның реестрын алып барудан;
- фондларның әлеге Закон тарафыннан вәкаләтле дәүләт органы компетенциясенә кертелгән эшчәнлеге мәсьәләләре буенча норматив һәм ысулый документларын әзерләүдән;
- әлеге Закон таләпләренең фондлар тарафыннан үтәлешен, шулай ук акча кертүчеләр һәм катнашучылар алдында аларның үз йөкләмәләрен үтәүләрен тикшереп торудан һәм законнар нигезендә башка вазыйфаларны үтәүдән.

### 30 статья. Фондларны дәүләт тарафыннан кызыксындыру

Дәүләткә карамаган пенсия фондларын дәүләт тарафыннан кызыксындыру дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары тарафыннан

280



икътисадый хуплауның төрле рәвешләрен үз эченә ала.

Фондка законнар нигезендә салым буенча өстенлекле ташламалар бирелә.

VIII бүлек. Йомгак нигезләмәләр

31 статья. Бәхәсләрне карау

Фонд белән юридик һәм физик затлар арасындагы бәхәсләр законнарда күрсәтелгән тәртиптә судта карала.

Татарстан Республикасы
Президенты
М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 24 июне
№ 1685